«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАРЫ**

**2020 елның 4 декабре** **№ 1**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы” территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән ,ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар) 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме ?"дигән сорау буенча, 2020 елның 30 ноябрендә, 1, 2, 3, 4 декабрендә этаплап узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыеннарының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

- Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган сугышчыларга мемориаль объектын ремонтлау
(смета нигезендә эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- ККК бункерларын сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 2041 катнашучысы кертелгән , тавыш бирүдә 1044 кеше катнашкан .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 954 кеше тавыш бирде;

"Юк" позициясе өчен җыенның 90 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы” территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән ,ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, биш һәм аннан күбрәк

балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар) 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме ?» соравы буенча карар кабул итәргә :

- Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган сугышчыларга мемориаль объектны ремонтлау

(смета нигезендә эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- ККК бункерларын сатып алу.

3.“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы” территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән ,ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар) 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган сугышчыларга мемориаль объектны ремонтлау

(смета нигезендә эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- ККК бункерларын сатып алу.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы р-н, Куйбышев Затоны штп., Ульяновск шоссесы ур., 12 й.
- ТР, Кама Тамагы р-н, Куйбышев Затоны штп., Куйбышев ур., 2А й.
- ТР, Кама Тамагы р-н, Куйбышев Затоны штп., Больничный тыкрыгы, 4 й.
- ТР, Кама Тамагы р-н, Куйбышев Затоны штп., Парковая ур.

шулай ук Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

« Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Куйбышев Затоны
шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль
берәмлеге башлыгы ,гражданнар җыенында
рәислек итүче Н.Б.Ефимов